Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында
ХӘБӘР ИТҮ

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итәбез.

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:

1) Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;
2) Территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре картасы;
3) Шәһәр төзелеше регламентлары.

Проект буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе һәм сроклары:

Гавами тыңлаулар 2026 елның 04 сентябреннән 2026 елның 23 сентябренә кадәр үткәрелә һәм түбәндәге этапларны үз эченә ала:
- гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү;
-гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны рәсми сайтта урнаштыру һәм мондый проектның экспозициясен яисә экспозицияләрен ачу;
-проект экспозициясен үткәрү;
- гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү;
- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе:
- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Иске Куак авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;
- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Иске Куак авыл җирлеге чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;
- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

Гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә Иске Куак авылында үткәрелә.

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Иске Куак авыл җирлегенең гавами тыңлауларда карау өчен җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектының экспозициясен 2026 елның 10 сентябреннән авыл җирлеге администрациясе бинасында ачарга:
- Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Иске Куак авылы, Заварыкин урамы, 36 йорт.

Проект экспозициясен үткәрү сроклары: 2026 елның 10 сентябреннән 2026 елның 22 сентябренә кадәр

Проект экспозициясе белән танышу вакыты – 9.00 дән 11.00 гә кадәр һәм 14.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр дүшәмбедән җомгага кадәр.

Экспозиция эше барышында «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына экспозициягә килүчеләргә консультация бирүне оештырырга.

Гавами тыңлауларда катнашучыларга җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектына кагылышлы үз тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен язма рәвештә, шул исәптән электрон рәвештә, түбәндәге адрес буенча кертергә тәкъдим итәргә: ТР, Лениногорск муниципаль районы, Иске Куак авылы, Заварыкин урамы, 36 йорт яисә Skuvak.Len@tatar.ru, 2026 елның 22 сентябренә кадәр, яисә 2026 елның 22 сентябрендә гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү барышында катнашучыларны исәпкә алу журналына язма рәвештә яисә телдән язып кую юлы белән.

Язма рәвештә тәкъдим ителгән искәрмәләргә һәм тәкъдимнәргә документларның күчермәләре дә кушып бирелергә тиеш: физик затлар өчен яшәү урыны буенча теркәлү турында тамга куелган һәм «Шәхси мәгълүматлар турында» 2014 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләр нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирү турында документның күчермәсе; юридик затлар өчен - ЕГРЮЛдан өземтә.

Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын билгеләргә:

22 сентябрь 2026 ел 16.30 сәг. адресы буенча: Иске Куак авылы, Заварыкин урамы, 36 йорт;

2026 елның 10 сентябренә кадәр җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын рәсми сайтта түбәндәге адрес буенча: https://leninogorsk.tatarstan.ru/ «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

Әлеге хәбәрнамәне Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендында урнаштырырга:

Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Куак авылы, Заварыкин урамы, 36 йорт.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Куак авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Сушкова И. Н.